КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 13 декабрь г.Казань № 1216

2022 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) турында

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән 2022 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 13 декабрь, 1216 нчы
карары белән расланды

## 2022 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы)

### I бүлек

### 2022 елда Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре

2022 елга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планнарын (программаларын) эшләү кагыйдәләрен раслау һәм Федераль мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турында карарлар әзерләү һәм кабул итү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында» 2005 елның 26 декабрендәге 806 номерлы карары белән расланган Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планнарын (программаларын) эшләү кагыйдәләре нигезендә, Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерүнең төп бурычларын исәпкә алып эшләнде.

2022 елда Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) гамәлгә ашыруның төп максаты – Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итүнең максималь эффективлыгын һәм аның табышлылыгын тәэмин итү.

Татарстан Республикасының икътисадый үсеше өстенлекләрен исәпкә алып, 2022 елда Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп бурычлары:

җитештерү-инновацион структураларга инвестицияләр җәлеп итү;

дәүләт мөлкәте составын һәм структурасын оптимальләштерү;

Татарстан Республикасы бюджеты керемнәрен формалаштыру.

Югарыда күрсәтелгән бурычларны хәл итү кысаларында 2022 елда Татарстан Республикасы милкендәге акционерлык җәмгыятьләренең акцияләрен хосусыйлаштыру планлаштырыла.

Фараз планына (программасына) кертелгән, финанс елы тәмамланганда хосусыйлаштырылмаган дәүләт мөлкәте чираттагы финанс елында хосусыйлаштырылырга тиеш.

2022 елда бу Фараз планына кертелгән акцияләр пакетлары торгларда сатылган очракта, аларны хосусыйлаштырудан Татарстан Республикасы бюджетына торглар барышында алынган суммада керемнәр керү көтелә.

II бүлек
2022 елда хосусыйлаштырылырга планлаштырыла торган
Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте

2022 елда акцияләре хосусыйлаштырылырга планлаштырыла торган
акционерлык җәмгыятьләре исемлеге

| Акционерлык җәмгыятенең исеме һәм урнашу урыны | «Алтын акция» булу | Устав капиталында Татарстан Республикасы өлеше, процент | Хосусыйлаштырылырга планлаштырыла торган акцияләр саны | |
|---|---|---|---|---|
| | | | данә | устав капиталы проценты |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Склад хуҗалыгы һәм ярдәмче транспорт эшчәнлеге | | | | |
| «Нижнекамскресурсы» акционерлык җәмгыяте, Татарстан Республикасы, Түбән Кама шәһәре | юк | 11,99 | 6 368 | 11,99 |
| «Бөгелмә элеваторы» акционерлык җәмгыяте, Татарстан Республикасы, Бөгелмә шәһәре | юк | 25 процентов + 1 акция | 94 473 | 25 процентов + 1 акция |
| Үсемлекчелек һәм терлекчелек, аучылык һәм бу өлкәләрдә тиешле хезмәтләр күрсәтү | | | | |
| «Алабуга икмәк кабул итү предприятиесе» ачык акционерлык җәмгыяте, Татарстан Республикасы, Алабуга шәһәре | бар | 7,69 | 2 566 | 7,69 |
| Әзер металл эшләнмәләр (машиналардан һәм җиһазлардан башка) җитештерү | | | | |
| «КАИ-Лазер» төбәк инжиниринг сәнәгать лазер технологияләре үзәге» акционерлык җәмгыяте, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре | юк | 71,73 | 437 167 892 | 71,73 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|
| Сәламәтлек саклау өлкәсендәге эшчәнлек | | | | |
| «9 нчы балалар стоматология поликлиникасы» акционерлык җәмгыяте | юк | 45,18 | 37 090 000 | 45,18 |